Бүгенге санда:




"Халык контроле" үз бурычларын үти. 2 бит

1931 елның 9 июленнән бирле чыга

# Дуслык

Дружба

Нурлат шәһәре һәм Нурлат районы газетасы

Чәршәмбе 24 июнь 2015 ел

№ 45 (10574)

25 июньгә һава торышы: аз болытлы һава, җил төньяктан 4-5 м/с; температура көндез +31°С, төнлә +23°С

ХӘБӘРЛӘРЕГЕЗНЕ КӨТӘБЕЗ

Телефоннар: 2-36-13, 2-36-20.

## *Абзац-информ*

### ПРИЗЫВНИКЛАР ЯНЫНДА

Дүшәмбе көнне район мәдәният идарәсе һәм хәрби комиссариат вәкилләреннән торган делегация республика Җыелу пунктында булып кайтты. Призывникларны тантаналы озату чарасында нурлатлылар үз сәламнәрен юлладылар, концерт программасы белән чыгыш ясадылар, призывниклар белән аралаштылар.

### ЮРИСТЛАР ТҮЛӘҮСЕЗ ЯРДӘМ ИТӘЧӘК

26 июньдә Нурлатта "Россиянең юристлар ассоциациясе" игълан иткән чираттагы Бөтенроссия түләүсез юридик ярдәм көне үтәчәк. Нурлатлылар үз сорауларына җавапны "Бердәм Россия"нең җирле бүлекчәсе җәмәгать кабул итүе бүлмәсендә (Совет ур., 96, 3нче кат) иртәнге 8дән кичке 4кә кадәр ала алалар. Белешмәләр өчен **тел.: 2-28-24.**

### "УЯВ" ЧАКЫРА!

27 июнь, шимбә көнне Нурлатта "Уяв" IX Бөтенроссия чуваш милли мәдәнияте бәйрәме узачак. Бу көнне мәйданда традицион остакуллар күргәзмәләре эшләячәк, ир-егетләр билбау көрәшендә – "Чуваш баһадиры", кызлар "Чуваш чибәре" исеме өчен көрәшәчәк. Республика һәм Россиянең фольклор коллективлары үзләренең иң матур чыгышларын бүләк итәчәк. Бәйрәм иртәнге 9да аэропорт мәйданында башлана.

### Район Советы аппараты хәбәр итә.

Район башлыгы Равил Кузюров исеменнән социаль челтәрдә күптән түгел ачылган бит – уйдырма. Бу хакта безгә район Советы аппараты җитәкчесе Олег Микушкин хәбәр итә. Чит кеше исеменнән бит ачучыны җитди җаваплылык көтәргә мөмкин.

*Район башлыгы аңлатмасын 2нче биттән укыгыз.*

# Марат Әхмәтов: *"Без үзебездән торганны эшләргә тиешбез"*



Автор фотосы

МИНИСТР МАРАТ ӘХМӘТОВ РАЙОН БАШЛЫГЫ РАВИЛ КУЗЮРОВ, "НУРЛАТ СӨТЕ" ҖӘМГЫЯТЕ ИНВЕСТОРЫ ШАМИЛ ЯҢУДИН, "АГРОИНВЕСТ" ИК ГЕНЕРАЛЬ ДИРЕКТОРЫ РӘИС СӨЛӘЙМАНОВ БЕЛӘН

**Узган атна азагында Нурлат районына ТР вице-премьеры - республиканың авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Әхмәтов килеп китте.**

Аны "ВЗП-Билярск" җәмгыятенең Колбай Морасадагы арыш басуында район башлыгы Равил Кузюров һәм "АгроИнвест" ИК ОООсы генераль директоры Рәис Сөләйманов каршы алдылар. Кыска вакытлы аралашудан һәм район басуларын вертолеттан карап әйләнгәннән соң, Марат Әхмәтов "Южная" агрофирмасының 226 гектарлы "Казанская-560" сортлы уҗым бодае басуында тукталды. Биредә ул район хуҗалыклары җитәкчеләре, белгечләре, авыл җирлекләре башлыклары белән очрашты.

Район башлыгы быел язгы кыр эшләренең бердәм булып, оператив срокларда башкарылуын, кырларны карауга зур игътибар бирелүен әйтте. Бүгенге көндә районда бар көч азык әзерләүгә юнәлтелгән, бер шартлы терлеккә 8 центнерлап бөрәмлек азык әзерләнгән.

Әмма Нурлат районында айдан артык яңгыр юк. Министр корылыктан ярылган җир һәм дымга сусаган уҗым сабакларына игътибар итте һәм бу уңайдан үзенең борчылуын белдерде. Кызганычка каршы, мондый хәл тулаем республика буенча күзәтелә һәм яздан планлаштырылган иген уңышы планкасын төшерү куркынычы тудыра.

– Әмма өметне югалтырга ярамый. Кайдадыр яфрактан тукландырырга, кайдадыр башка агротехник чаралар күрергә кирәк, - диде министр һәм шунда ук район игенчеләренең хезмәтенә дә бәясен бирде: – Нурлат районы элек-электән югары игенчелек культурасы белән аерылып торды. Быел да игенчелектә күп эш башкарылган, күп кертемнәр ясалган. Эре авыл хуҗалыгы предприятиеләренең басулары бик әйбәт тәэсир калдырды, вак фермер хуҗалыкларына да бу традицияне сеңдерәсе бар.

Шунда ук районда чөгендер плантацияләренә нык игътибар бирергә чакырды.

Очрашуда Марат Готович тулаем республика буенча хәлгә дә күзәтү ясады. Авыл җирлекләре башлыкларына да яңалыклар җиткерде. Быел шәхси хуҗалыклардагы савым сыерларга бирелә торган субсидияне 3 мең сумга җиткерү күздә тотыла, диде ул. Бөтен социаль программаларның да үтәлүен искәртеп, республика җитәкчелегенең авыл хуҗалыгыннан да яхшы нәтиҗә көтүен басым ясап әйтте.

– Максималь уңыш алу өчен без үзебездән торганның барысын да эшләргә тиеш, – диде ул, якын көннәрдә Нурлат басуларына да яңгырлар килүен теләп.

Лилия **МӨБАРӘКШИНА**

КӨН КАДАГЫНДА

# Эссе җәй сыный

**Татарстан Гидрометеоүзәге хәбәр иткәнчә, бу көннәрдә республика территориясендә аномаль эссе һава торышы күзәтелә, ә тәүлеклек уртача температура нормадан 9 градуска артып китә.**

Янә 2010 елның җәе кабатланыр микәнни? Безнең район территориясендә тәүлеклек уртача һава температурасы нормадан 4-8 градуска артыграк.

– Бу көннәрдә һава торышының максималь күтәрелүе 36 градус тәшкил итте, – ди Чулпан метеостанциясе начальнигы Наталья Матвеева. – Аномаль эссе һава безнең территориядә бер атна диярлек булачак, алдагы көннәрдә дә эссе һава торачак. Көньяк циклон килү белән кайбер урыннарда кыска вакытлы яшенле, бозлы көчле яңгырлар һәм җилнең секундына 20-24 метрга кадәр көчәюе көтелә. Аномаль эсселек явым-төшемнең азлыгы белән дә кискенләшә. Майдан бирле нормадан 40 процент кына явым-төшем булды.

Авыл хуҗалыгы – корылыкны аеруча нык сизүче тармак. Районның авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе белгечләре әйтүенчә, мондый һава торышы аркасында бөртекле культураларның вегетация чоры кыскара икән. Һәм бүгенге көндә иң тәҗел нәрсә – яңгыр, туфрактагы дым критик хәлдә.

Моннан тыш, челлә сәламәтлеккә дә йогынтысын ясый.

– Мондый аномаль эседә урамда азрак йөрергә, күп итеп сыеклык эчәргә, әмма газлы су, алкоголь яисә шикәр микъдары күп булган эчемлекләр булмасын. Иң яхшысы – су, чәй, минералка, – дип киңәш итә район хастаханәсенең баш табибы урынбасары Татьяна Соренкова. – Бу көннәрдә эссе каккан пациентлар булмады үзе, әмма шулай да киемнәргә игътибар бирергә кирәк: ул һава торышына туры килергә тиеш, натураль тукымадан булсын, һичшиксез, башка кияргә. Хәзер һава дымлылыгы 9 процентлар тирәсе, ә кеше өчен 30-60 процент җайлы санала. Шуңа да физик нагрузкаларны азайтырга, энергияне сакларга кирәк.

*(Ахыры 3нче биттә)*



**ӘБУНӘЧЕЛӘР, СӨЕНЕГЕЗ!**

**Сезнең өчен ике шатлыклы хәбәр: 2015 елның икенче яртыеллыгына әбунә кампаниясе һәм призлы язылу 4 июльгә кадәр озайтылды.**

**26 июньдә редакциядә Әбунәче көне үткәрелә. Бездән–призлар, бүләкләр, сездән–сораулар, тәкъдимнәр.**

**Форсатны кулдан ычкындырмагыз!**

БАСУЛАРДА




ШӘҮКӘТ МИНДУБАЕВ БЕЛӘН ИЛШАТ ХӘЙРУЛЛИН БАСУДА

# Яуга "картлачлар" чыга

**Колбай Морасадан Шәүкәт Миндубаев һәм Илшат Хәйруллин үзара шулай шаяралар. Икесенең дә авыл хуҗалыгындагы тәҗрибәләре шактый саллы. Хәтта лаеклы ялга чыккач та тик утыра алмаганнар, әле дә хезмәттә алар.**

"ВЗП-Билярск" ОООсы "ветераннары" белән без кукуруз басуында очраштык, анда аммиак селитрасы белән өстәмә тукландыру белән рәт аралары эшкәртү бара иде. Шәүкәт Миндубаев соңгы елларда хуҗалыкта тимерче булып эшли. Аңа кадәр механизатор да булган, чөгендер дә иккән. 1969 елда Бөгелмә СПТУсын бик яхшыга тәмамлап, туган авылына кайта, җирле хуҗалыкка урнаша, һәм бүгенгәчә шунда. Без килгәндә ул авыл хуҗалыгы академиясеннән студент-практикант Ирек Мусин белән ашламалар төяп торуда иде. Илшат Хәйруллин иярләгән трактор чираттагы әйләнештән соң, позициягә басуга, Шәүкәт Солтанович ярдәмчесе белән вакытны озакка сузмый ашлама тутыра башлый. Шул арада Илшат Таһирович белән бер-ике сүз алышырга өлгерәбез. Аның стажы 45 ел чиген узган инде. Һәм шул чор эчендә хуҗалык басуларын күпме әйләнгәндер – күзаллавы да кыен. Чәчүдә дә эшли, урвак чорында комбайнга да утыра. Ә хәзер өстәмә тукландыруда мәшгуль. Кукуруз кырыннан соң, көнбагышныкы көтә. Ә аннан инде уракка да ерак калмый.

– Ашламаны гектарына 1 центнер исәбеннән кертәбез. Бу кукуруз бөртеккә китәчәк. Аны быел хуҗалыкта 680 гектар чәчтеләр, шуның 180е – силоска, – ди отряд начальнигы Рәшит Сафин.

Игенчеләр әйтүенчә, уңыш начар булмаска охшаган, һава торышы гына комачауламасын. "Яңгыр җитми", – дип сукраналар алар.

Хуҗалыкта берүк вакытта азык әзерләү эше дә дәвам итә. Люцерна кырында чапкычлар тавышы тынмый. Ягулыгын да шунда ук салалар, төшке ашын да бирегә китерәләр.

– Эшне бер сменада оештырдык, иртәнге 6дан кичке 8гә кадәр. Эш күләмен җиңәр өчен шул җитә, – ди отряд начальнигы.

Люцерна 180 гектарда чәчелгән, тагы 102 гектарда костер бар. Беренче укос яхшы нәтиҗәләр биргән. Кичәге көнгә 1700 тонна сенаж әзерләнгән, бу планнан 100 процент. Печәнне 25 тонна әзерләгәннәр, планны тутырыр өчен тагы шулкадәр кирәк. Бүген хуҗалыкта 700 баш мөгезле эре терлек бар, тиздән тагы 200 савым сыер алып кайтырга тиешләр. Димәк, алар өчен азыгын да алдан әзерләп кую мәслихәт.

Маргарита ЛИТТА

# Эссе җәй сыный

*(Ахыры. Башы 1нче биттә.)*

Яңгырлар юклыгы су белән тәэмин итүдә дә чагылыш таба.

– Су куллану ике тапкырга артты, – диде "Промочистка"ның баш инженеры Анатолий Анисимов. – Шәхси сектордa бакчаларында су сибү системаларын төне буена сүндерми калдыручылар да бар.

Баш инженер шикәрчеләр һәм тимер юлчылар бистәләрендә, скважиналарның аз булуы сәбәпле, суны сәгатьләп бирү ихтималлыгы турында да әйтте. Әмма су белән тәэмин итүдә өзеклекләр була калса да, балалар учреждениеләре, хастаханә сусыз калмаячаклар – бирегә аны китереп торачаклар.

Сирень СӘМӘРХАНОВА

БУРЫЧЛЫЛАР

# Сусыз калуың да бар

**Элегрәк фатир өчен бурычлыларның электр һәм газларын гына өзәләр иде, хәзер, "Су белән тәэмин итү һәм су түгү турында"гы Федераль законның 21нче маддәсе нигезендә, ресурс саклаучы оешмалар су бирү һәм су түгүне (канализация) туктатып тора яки сүндерә алачаклар.**

Узган атнада "Бердәм исәп-хисап үзәге", суд приставлары, полиция, ТСЖ вәкилләре йорт-лар буйлап рейд уздырдылар. Бу юлы рейд төркеме Мәскәү ур., 5, Циолковский ур., 7, 9 һәм 11нче йортларда булып чыкты.

– Бу йортлардагы иң зур бурычлы – Мәскәү урамындагы йортның фатир хуҗасы – аның әҗәте 104 мең сум тәшкил итә, – диде "ЕРЦ-Нурлат"ның ТКХ өчен бурычларны түләттерү буенча белгече Венера Мингалиева. – Моннан тыш, 4 бурычлы Циолковский ур., 7дә яши, һәм иң зур бурыч – 22 мең. Циолковский ур., 9да 6 бурычлы, иң зурысы 30 мең, 11нче йортта 62 мең сумнан артык, биредә әҗәтләр дә күбрәк – 13әү.

Рейд барышында суд приставларының үз бурычлары иде: алар башкарма производство ачылган затлардан бурычларын түләттерер өчен чакырылдылар.

– ТКХ түләүләренең җыелу дәрәҗәсен арттыру өчен бурычлының эш урыны турында мәгълүмат җыела, бу предприятие җитәкчеләре ярдәме белән әлеге бурычлыларга йогынты ясау ысулларын табар өчен эшләнә, – диде "ЕРЦ-Нурлат" директоры Чулпан Сөләйманова.

Рейд нәтиҗәләре буенча бурычлыларга әҗәтләрне түләү срогы күрсәтелгән судка кадәрге уведомлениеләр тапшырылды. Әгәр шуннан соң да түләү кермәсә, бурычлыларга карата судка шикаять язылачак. Хәзерге вакытта Пионер ур., 1, Нефтьчеләр ур., 8, Совет ур., 114 йортларында яшәүче һәм торак-коммуналь хезмәтләр өчен усал нияттән түләмәүче өч бурычлыны фатирларыннан сөреп чыгаруга документлар әзерләү бара.

Сирень СӘМӘРХАНОВА

"АВТОЛЕДИ-2015"

# Натальяның алтынчы җиңүе

**"Автоледи" машина йөртү осталыгы район конкурсында быел алтынчы тапкыр Наталья Львова җиңде. Ул конкурсның республика финал өлешендә район данын яклаячак.**

Узган шимбәдә районның иң матур, оригиналь, актив һәм максатка омтылышлы гүзәл затлары үзләрен тагын бер кат машина йөртү осталыгында сынап карадылар. Конкурсантлар ярышларның ике этабы – теоретик һәм гамәли турын узарга тиеш иде.

Беренче этапта юл хәрәкәте кагыйдәләре, автомобиль белән имин идарә итү нигезләре, юл хәрәкәте иминлеге өлкәсендәге законнар буенча белем тикшерелде. Монда 20 сорауга 1 минут 59 секунд эчендә җавап биргән Наталья Львовага тиңнәр булмады.

Икенче этап – гамәли бәйге. Монда осталык белән беррәттән, тәҗрибә дә булу шарт. Бу көнне конкурста катнашкан 5 гүзәл затны да техниканы һәм тизлекне ярату теләге берләштерде. Кызлар тиешле вакыт эчендә җиңел машина белән катлаулы күнегүләр ясап күрсәттеләр.

– Статистика буенча, хатын-кызлар гаебе белән юл-транспорт һәлакәтләре азрак ясала, – ди ЮХИДИнең пропаганда инспекторы Ринат Мөгайнетдинов. – Хатын-кызлар руль артында ир-атларга караганда төгәлрәкләр. Бәлки, бу әлеге конкурслар нәтиҗәседер дә.

ЮХИДИ мәгълүматлары буенча, 15 ел рәттән уткәрелүче район конкурсында яшь буенча чикләүләр юк. Әмма ни өчендер соңгы елларда әлеге конкурска кызыксыну кимегән.

– Алдагы елларда конкурста катнашырга теләүчеләр 10нан артып китә иде, – ди районның Юл хәрәкәте иминлеге фонды дирекциясенең Нурлат бүлеге директоры, үзе дә 20 ел машина йөртү стажына ия Гөлфия Гыймалетдинова. – Әмма соңгы вакытта руль артына утыручы гүзәл затлар арта барса да, конкурста катнашучылар саны кими. Ә минә быелгы конкурста катнашучыларыбызның һөнәрмәнлегенә кызтимәсен. Мин, жюри әгъзасы һәм машина йөртүче буларак, конкурсантларның барысына да яхшы билгеләре генә куям.

Конкурс шартлары елдан-ел катлаулана барса да, катнашучыларны бу куркытмый икән. Әнә, нурлатлы Марина Билданова конкурста соңгы тапкыр 2003 елда катнашкан булган.

– Юл кагыйдәләре ел саен үзгәреп тора, шуңа да даими өйрәнеп, кабатлап торырга кирәк, – ди ул үзе.

ЮХИДИ бүлеге начальнигы Рөстәм Гарипов әйтүенчә, киләсе елдан "Автоледи" республика конкурсының район этабында Нурлат шәһәре һәм районы юлларына кагылышлы сораулар да кертеләчәк икән.

– Иң мөһиме, юлларыбызда иминлек булсын, ә мондый конкурслар осталыкны чарлау ягыннан файда китерсен, – диде Рөстәм Рамилевич конкурсантканаларны котлау вакытында. Бу көнне аларга кыйммәтле бүләкләр, грамота һәм Кубоклар тапшырылды.

Җиңүче автоледи Наталья Львова конкурсның файдасы зур булуын билгеләп үтте.

– Статистикадан күренгәнчә, районда һәр бишенче хатын-кыз руль артында, – ди Наталья. – Шуңа да аларга




АВТОЛЕДИНЫ РАЙОННЫҢ БАШ ЮЛ ИНСПЕКТОРЫ КОТЛАДЫ

конкурста катнашып, тагын бер кат үз белемнәрен тикшерүдән курыкмаска киңәш итәм, – ди җиңүче. 14 яшеннән машина руле артына утырган Наталья өчен сайлап алу туры бәтенләй кыенлык тудырмады бугай. 19 ел машина йөртү стажы булган Натальяның беренче тапкыр иярләгән машинасы ВАЗ-2106 булган икән. Шул еллар эчендә "Шевроле Шпарк", "Шевроле Лачетти", "Рено Дастер" машиналарына күчеп утырырга өлгергән ул. Машина маркасы нинди булса да, шофер өчен иң беренче чиратта белем, игътибар һәм тәҗрибә кирәк – Наталья шуңа инанган, һәм ул аны җиңүгә китергән дә.

Зилия ӘКСАНОВА

ЙОЛАЛАР



МӨСЕЛМАННАР ҮЗ ТЕЛӘКЛӘРЕ КАБУЛ БУЛЫР, ДИП УЙЛЫЙЛАР

# Нурлат мөселманнары яңгыр тели

**9 майдан районда коры һава торышы саклана. Белгечләр чаң суга: тагын берничә көн шундый һава торышы сакланса, игеннәр юкка чыгарга мөмкин, диләр. Шуңа да районның дин әһелләре корылыкка каршы көрәштә яңгыр теләп, Аллаһка ялварырга булдылар.**

Узган якшәмбедә район аксакаллары “Юлдаш” чишмәсе буена яңгыр сорап намазга җыелдылар. 2 рәкагать намаз, хөтбә һәм Коръән сурәләре укып дога кылынды. Намаздан соң вәгазь дә сөйләнде.

– Узган елларда шундый намазлар үткәреп хәерле, файдалы яңгырлар сорагач, нәтиҗәсе озак көттерми иде, – ди район мөхтәсибе Айрат хәзрәт Әюпов. – Иншалла, быел да яңгырлар булыр дип өметләнәбез. Яңгыр сорау – ул сөннәт гамәле. Шуңа да бүген сөннәт намазы укылды. Истиска намазы Пәйгамбәребез вакытыннан бирле укылган. Мөхәммәт пәйгамбәребез үзенең хәдисендә кешеләр Аллага ышанып һәм аның барлык таләпләрен үтәп яшәгәндә, халыкка файдалы җилен дә, яңгырын да бирермен, дигән бит.

Айрат хәзрәт Әюпов намаздан соң җыелган халыкны гөнаһлардан тәүбә кылырга, булган бурычларны түләргә, кыерсытылганнардан гафу үтенергә, ятимнәргә сәдака бирергә, игелекле гамәлләр башкарырга чакырды.

Чарада катнашкан мөселманнар районда яңгыр юклыкны гошер сәдакасы бирмәү белән дә бәйлиләр.

– Халык гошер сәдакасы турында онытты, – ди Кормыш бистәсе мәчете имамы Габделхак Шәяхмәтов. – Уңышны җыеп алгач та, аның бер өлешеннән гошер сәдакасы бирелергә тиеш. Әмма бездә бу эш бөтенләй башкарылмый.

Ачык һавада сөйләнгән вәгазь үтемле була, диләр. Яңгыр сорау намазларын район мөхтәсибәте аксакаллары икенче көнне татар авылларында да башкардылар.

Зилия ӘКСАНОВА

ӨЙРӘНҮЛӘР

# Бурычларны үтәргә әзер

**Күптән түгел районда радиацион һәм химик торышны бәяләү буенча штаттан тыш расчет-аналитика төркемнәре белән команда-штаб өйрәнүләре үтте.**

Анда күзәтү һәм лаборант контроле челтәренә керүче учреждениеләр дә җәлеп ителде.

Тренировкалар барышында зарарланган зоналарның тирәнлеген һәм мәйданнарын, алар йогынтысына эләгү ихтималы булган халыкның санын билгеләү, пробалар әзерләү һәм сайлау кебек мәсьәләләр каралды. “Уздырылган тренировкаларны анализлау Нурлат районы буенча янгын сагы гарнизонының хисап материалларын тулысынча тәкъдим итүен күрсәтте”, – диде гражданнар оборонасы өлкәсендә вәкаләтләрне билгеләү бүлегенең Нурлат районы буенча әйдәп баручы консультанты Фәридә Борһанова.

Тренировкалар нәтиҗәләре буенча, Нурлат гарнизоны куелган бурычларны үтәргә әзер, дигән нәтиҗә ясалды. Әйдәп баручы белгеч әйтүенчә, тренировкаларга әзерлек эшләрендә зур эш башкаручылар арасында Нурлат районының Гигиена һәм эпидемиология үзәге баш табибы Илдус Әхмәтҗанов, 125нче янгын часте начальнигы Илһам Курамшин, шулай ук әлеге службаларның коллективлары бар.

Сирень СӘМӘРХАНОВА

УҢЫШ



ИҖАДИ ЭШ РУФИНӘГӘ УҢЫШ КИТЕРДЕ

# Эше музейда сакланачак

**Колбай Мораса урта мәктәбе 4нче сыйныф укучысы Руфинә Галиуллина “Газпром трансгаз Казан” җәмгыяте 60 еллык юбилее уңаеннан “Гаилә һәм мәктәп” журналы белән берлектә үткәргән “Зәңгәр ягулык җылысы” проектында катнашып, “Кроссворд” номинациясендә 1нче урын яулады һәм кыйммәтле бүләк – планшетка ия булды.**

Бу бәйгедә Руфинә узган елда да җиңү яулаган иде. Быел исә Руфинәнең һәм аның җитәкчесе, мәктәпнең татар теле һәм әдәбияты укытучысы Рәмзия Галиуллинаның фантазиясе оештыручыларны да шаккатыра - Газпромның зәңгәр ягулык символын агач макетта ясап, кроссвордны шуның арткы ягына төшерәләр алар һәм берсүзсез җиңүче итеп табылалар. “Гаилә һәм мәктәп” журналында исә алар турында: “Нурлат районыннан Руфинә Галиуллинаның эшен күреп, редакциябез “аһ” итте”, - дигән юллар бар.

Әлеге бәйгедә быел 150 кеше катнашып, бары 9сы гына җиңүчеләр исемлегенә кергән. Җиңүчеләрне бүләкләү исә узган атна азагында җәмгыятьнең музеенда үткән. Руфинәнең җиңү яулаган оригиналь кроссворды да хәзер шунда урын алган икән.

Лилия МӨБАРӘКШИНА

ХӘБӘРЛӘР

## ЯҢА ЕПИСКОП БУЛЫП КИТТЕ

Шимбә көнне Нурлатта Чистай һәм Түбән Кама кафедрасына билгеләнгән яңа епископ Пармен булып китте.

Иң элек ул Мамыктагы Николай Чудотворец приходында булды. Анда епископ район башлыгы Равил Кузюров белән очрашты. “Бирedә яхшы кешеләр яшәгәнлеге күренеп тора, приходлар да бик чиста”, – диде епископ Пармен.

Район башлыгы епископны актив хезмәттәшлеккә чакырды һәм “Уяв” чуваш мәдәнияте бәйрәмендә көтеп калабыз, диде. Аннан епископ Төрнәс, Иске Чаллы, Биляр Озеро, Елаур православия приходларында, Преподобный Серафим Саровский гыйбадәтханәсендә һәм Егоркинодагы чиркәү төзелешендә булды.

## ИҢ ЯХШЫСЫ – ИСАЕВА ГАИЛӘСЕ

19 июньдә тәрбиягә бала алып үстерүче һәм опекун гаиләләрдә үсүче малай-кызлар өчен традицион балалар Сабантуе үтте.

Бәйрәмгә Бөгелмә, Спасс районнарыннан да шундый гаиләләр чакырылган иде. Балалар Сабантуенда зур кунаклар да булып киттеләр. Иң элек барысын да ТР Президентының эчке сәясәт мәсьәләләре Департаменты дини берләшмәләр белән хезмәттәшлек Идарәсенең дәүләти конфессиональ мөнәсәбәтләр бүлеге баш киңәшчесе Руслан Мәрданшин сәламләде. Ул барысын да бәйрәм белән котлады. “Нурлат районында ятим балаларга ярдәм итүгә юнәлдерелгән хәйрия эше яхшы үсеш алган. Бу уңайдан сезнең тәҗрибәне уртаклашырга була”, – диде ул. Һәм мисал буларак “КОСиГ” кече нефть компаниясен атады, алар ел саен балалар Сабантуеның төп иганәчеләре булып, балаларны бүләкләр белән сөендерәләр. Бәйрәмдә гадәттәгечә “Елның иң яхшы тәрбиягә бала алып үстерүче гаиләсе” конкурсына да йомгак ясалды. Күчмә Кубокны Нурлаттан ялгызы 4 баланы тәрбиягә алып үстерүче Елена Исаева яулады.

Маргарита ЛИТТА

## НЕКРАСОВКАДА – БАЛАЛАР САБАНТУЕ

Икенче ел рәттән Яңа Иглай авыл җирлегенә кергән барлык авылларда яшәүче балалар өчен Некрасовка поселогы янындагы ямьле әрәмәлектә Балалар Сабантуе үтә. Быел да авыл балалары бәйрәмне зарыгып көтеп алганнар һәм бик теләп катнашканнар. Оештыручылар – авыл җирлеге башкарма комитеты, мәдәният, мәгариф учреждениеләре хезмәткәрләре балаларның яшь үзенчәлекләрен исәпкә алып, төрле ярышлар, бәйгеләр үткәргәннәр. Балаларның күңел ачуын карарга әти-әниләр белән бергә әби-бабайлары да килгәч, чара гаҗәеп күңелле гаилә бәйрәменә әверелгән. Яңа Иглай авыл җирлегендә Балалар Сабантуен традицион бәйрәм итмәкчеләр.

## ГАИЛӘ ФЕРМАСЫНА – ДӘҮЛӘТ ЯРДӘМЕ

Республикада “Татарстанда 2015–2017 елларда КФХлар базасында гаилә терлекчелек фермаларын үстерү” федераль ведомство программасы буенча грантлар отучы 41 фермер арасында Яңа Әмзәдән Алмаз Корбанов та бар. Крестьян-фермерлык хуҗалыгы башлыгы грант акчаларын гаилә фермасын үстерүгә тотарга ниятли.

- Бүгенге көндә 33 баш мөгезле эре терлек асрыйбыз. Шуларның 13е – савым сыер, - ди фермер. – Грант ярдәмендә 24 башка исәпләнгән заманча ферма төзиячәкбез, савым сыерларның баш санын арттырачакбыз.

Бу көннәрдә Корбановларның гаилә фермасында эшләрнең кызган чагы – печән өсте. Гаилә 76 гектарда үстерелгән печәнне беренче катка чаптыру белән мәшгуль. Моннан тыш, 60шар гектарда арпа һәм бодай да үстерәләр әле, аларны саклап үстерү буенча да мәшәкатьләре җитәрлек. Ә грант хуҗалыкларын тагы да үстерүгә яхшы стимул булачак, диләр Корбановлар.

Лилия МӨБАРӘКШИНА

ИМИНЛЕК

## ТИКШЕРҮЛӘР БАРА

18-30 июньдә 73нче янгын частенең инженер-инспекторлык составы “Нурлатнефть” идарәсе һәм “Татнефтеотдача”ның 2нче ЦДНГсы объектларын тикшерә. Бу чара технологик процессларны бозу, производство җиһазының төзексезлеге, янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен үтәмәүдән килеп чыгучы янгыннарны профилактикалау максатларында уздырыла.

Альберт НАСЫЙБУЛЛИН,

73нче ЯЧ инженеры

***

“Нурлатнефть” НГДУсының Андреевкадагы объектында 73нче янгын часте комплекслы өйрәнүләр уздырды. Анда частьның барлык структуралары, коткаручылар җәлеп ителде. Мондый өйрәнүләр өч елга бер уздырыла, нәтиҗә уңышлы булды, диләр янгын частенда.

# ТӨРЛЕ. РЕКЛАМА

МАВЫГУ

## Алтын куллы оста


Автор фотосы

ЮРИЙ МАТВЕЕВ ҮЗ КУЛ ЭШЛӘРЕ БЕЛӘН

**Урта Камышлыдан Юрий Матвеев агач турында барысын да белә. Һәм бу аның һөнәре буенча урман белгече булуына, озак еллар урманчы булып эшләвенә генә дә бәйле түгел. Иң мөһиме – аның кулларында агач сәнгати әсәргә әверелә.**

Хәзер Юрий Сириусович "ТНГК-Развитие" җәмгыятендә оператор булып эшли. Эш графигы җайлы булганлыктан, аның яраткан шөгыленә вакыты күп кала.

– Менә монысы карама тамыры, урманда йөргәндә таптым, – дип сөйли үз эшләнмәсе турында ул. Оста673 тырышлыгы, фантазиясе, иҗади карашы – һәм менә безнең каршыбызда гаҗәеп киштә, агачның боргаланып төшкән балсыман төсләреннән төрле әкият геройларын танырга була.

Агачка, иҗатка мәхәббәт Юрий Сириусовичта балачактан ук килә, аларның гаиләсенә дә һәрчак иҗади кызыксыну хас була. Хәзер аның балалары җансыз агачның форма алуын һәм "терелүен" сокланып күзәтәләр. Җәмәгате Лариса Валерьевна белән алар өч бала үстерәләр. Тормыш иптәше дә иренең һәм балаларының бу шөгылен хуплый. Өлкән уллары Саша да әтиләренең шөгылен үз иткән һәм Самара сәнгать училищесын тәмамлаганнан соң, Казанда дизайнер булып эшли. Төпчекләре Даша һәм Миша мәктәптә укыйлар әле.

– Миңа агач белән шөгыльләнүнең үземнең күңелемә хуш килүдән тыш, моңа балаларның өйрәнүе дә ошый әле, – ди оста. – Заманында мәктәптә түгәрәкләр алып бара идем.

Игътибар беләнрәк карасаң, останың һәр эшләнмәсенең үз холкы. Җиһаз киштәләренә индивидуальлек хас, һәркайсының – үз төсмере. Әлеге агач эшләнмәләргә карасаң, алардан ниндидер үзенчәлекле йомшак һәм яшәү көче өстәүче энергия бөркеп тора сыман. Аларны эшкәрткәндә, оста агачның структурасына зур игътибар бирә, нәкъ әнә шул тормыш бөҗралары, тамырлары кабатланмас иҗат җимеше тудыра да. Шул рәвешле останың өендә искитмәле филләр, кошлар, киштәләр үз урынын алган һәм һәркемгә матур кәеф биреп тора.

Валентина ВАФИНА

ХӘТЕР КӨНЕ

## Рәхмәт сүзләре һәм искә алу

**Дүшәмбе, 22 июнь көнне нурлатлылар Бөек Ватан сугышында үз гомерләрен биргән фронтовиклар һәм тыл хезмәтчәннәрен искә алдылар.**

Инде иртәнге 9да Хәтер һәм Дан аллеясенә предприятие, мәктәп коллективлары, район һәм шәһәр җәмәгатьчелеге чәчәкләр, веноклар салдылар. 10да Хәтер һәм кайгы көненә багышланган митинг башланды. Район башлыгы Равил Кузюров, ветераннар Советы рәисе Разия Садретдинова ветераннар адресына рәхмәт сүзләре җиткерделәр, сугышта һәлак булганнарны искә алдылар.

Валентина ВАФИНА

МАВЫГУ

## Футболчылар кече күңелле була

**Күптән түгел АТП футбол командасы Нурлатта инвалид балалары булган тәрбиягә бала алып үстерүче гаиләләргә ярдәм итү акциясе оештыру инициативасы белән чыктылар.**

Берничә көн алдан алар 10 мең сум акча җыйдылар. Сумманы ике гаиләгә бүлделәр. Һәм 19 июньдә, балалар Сабантуенда команда җитәкчесе Марат Хәмидуллин әлеге акчаларны Васильевлар һәм Пироговлар гаиләләренә тапшырды. Алар исә футболчыларга чын күңелдән рәхмәтләрен җиткерделәр һәм акция традиционга әверелер, дигән өмет белдерделәр. Чөнки мөмкинлекләре чикләнгән балалары булган гаиләләр өчен матди ярдәм кайчагында бик тә кирәк була.

– Хәйрия акциясе дәвам итә. Футболчыларның игелекле башлангычы барлык нурлатлыларга да үрнәк булыр дип ышанасы килә, – дип билгеләп үтте үз чиратында команда тренеры Марат Хәмидуллин.

Бәйрәмдә тәрбиягә бала алып үстерүче гаиләләрдәге сабыйларны ишегалды футбол командаларына җәлеп итәргә кирәк, дигән тәкъдим дә яңгырады.

Маргарита ЛИТТА

УҢЫШ

## "НУРЛАТ" ТРКсы ДИПЛОМЛЫ БУЛДЫ

"Нурлат" ТРКсы "Гаилә һәм Россиянең киләчәге" Бөтенроссия журналистлар конкурсында катнашып, Диплом белән бүләкләнде. Дипломга Милли дан һәм Андрей Первозданный фонды вице-Президенты Н.Якунина кул куйган.


Требуются охранники с лицензией и без лицензии для работы на промышленных объектах в городах Димитровград, Тольятти.
График работы - *две недели через две.*
Официальное трудоустройство. Бесплатное 3-х разовое питание, бесплатная доставка до объекта, проживание.
З/п 850-900 руб. сутки для охранников без лицензии, 1000-1150 руб. сутки с лицензией (на руки).
Аванс.
Т.: 8-937-986-76-81, 8-937-459-53-00.

НАТЯЖНЫЕ ПОТОЛКИ ПЛАСТИКОВЫЕ ОКНА АВТОМАТИЧЕСКИЕ ВОРОТА
8-927-444-22-88.

ОО «Гарантия качества» предлагает ПЛАСТИКОВЫЕ ОКНА европейского качества по доступной цене заводского производства. Рассрочка без %, без участия банка.
Т. 8-927-405-53-52.

ООО «МИР КРОВЛИ»
реализует
ПРОФНАСТИЛ С9, С20, С21, НС44, Н60, Н75 (оцинкованный и окрашенный), длина до 12 метров, металлочерепицу, металлосайдинг, металлоштакетник, профильную трубу, гладкий лист, доборные элементы. Утеплитель. Парогидроизоляция. Поликарбонат. Теплицы.
Доставка по городу бесплатно.
Гарантия на всю продукцию.
Т.: 8-927-826-53-32, 8-937-273-87-15, 8(84235) 2-75-35, 2-72-25.
E-mail: mir-krovli73@bk.ru

УСЛУГИ АВТОКРАНА
25 ТН, ВЫЛЕТ СТРЕЛЫ 21 М.
8-927-444-70-80.

ООО «РНК» реализует следующие виды материалов и инструментов:
- кабель геоф. КГ 1*1,5*55*150 – 2505 метров,
- канат 6,2 мм – 1481 метров,- канат 9,1 мм – 524 метров,- винтовой забойный двигатель с верхним патрубком – 1 шт.,- манжета сваба RW2 ½ - R – 28 шт.,
- ключ КТ 89*132 – 2 шт., - ключ КТГУ 60 – 2 шт.,- ключ КТГУ 73 – 5 шт.,
- приспособление свинчивания развинчивания штанг – 3 шт.,- сверла разные – 228 шт.,
- укрытие для качалки с головкой – 1 шт.
Обращаться по тел.: 2-05-86, 2-05-81.
8-917-298-15-58.

ДОСТАВКА ПЕРЕГНОЙ, ЧЕРНОЗЕМ, ГРУНТ, ПЕСОК, ПГС, ДРОВА КОЛОТЫЕ, ЧУРБАКАМИ И ДЕФЕКАТ
8-937-280-94-84.

«KRAUSS» ПЛАСТИК ТӘРӘЗӘЛӘРЕ
2015 елның 1 гыйнвар- 31 декабрендә 5 тәрәзәгә заказ биргәндә, 6нчысы бүләккә*
Авыл тәрәзәләре 2000 сум.
Откослар, тәрәзә төпләре, москит челтәрләре.
Бөтен Татарстан буенча эшлибез.
%сыз бүлеп түләү (банклар катнашыннан башка).
*җентеклерәк 8-9274-000-606, 8-9272-449-000 тел. буенча.
«Свет-Окон» ООOсы.


**Извещение о проведении собрания о согласовании местоположения границы земельного участка.**

Кадастровым инженером Самигулова Г.Р. (nurlat_bti@rambler.ru тел. 8 (84345) 2-07-89; квалификационный аттестат №16-12-507) в отношении земельного участка с кадастровым номером 16:56:010158:38, расположенного по адресу: РТ, Нурлатский муниципальный район, г.Нурлат, ул. Садовая, д. 13твыполняются кадастровые работы по уточнению местоположения границы и площади.

Заказчиком межевых работ является Исхакова Разия Ибрагимовна.

Для проведения кадастровых работ необходимо произвести процедуру согласования части границы с правообладателями земельного участка с кадастровым номером 16:56:010158:37, расположенного: РТ, Нурлатский муниципальный район, г.Нурлат, ул. Овражная, д. 14.

Все заинтересованные лица с проектом границ уточняемого земельного участка могут ознакомиться по адресу: РТ, Нурлатский муниципальный район, г.Нурлат, ул. Гиматдинова 52, со дня опубликования извещения, будни от 8:00 до 17:00. При себе необходимо иметь документ, удостоверяющий личность, а также документы о правах на земельный участок.

Обоснованные возражения по прохождению границ уточняемого земельного участка 16:56:010158:38 принимаются со дня опубликования данного извещения в течении 30 дней, по адресу: Республика Татарстан, Нурлатский муниципальный район, г.Нурлат, ул. Гиматдинова 52 тел. 8 (84345) 2-07-89.

**Совет Бурметьевского сельского поселения**
**Нурлатского муниципального района Республики Татарстан**

### РЕШЕНИЕ

15 июня 2015 года №100

**О внесении дополнений в Решение Совета поселения от 12.01.2015 г. №87 «О назначении местного референдума на территории Бурметьевского сельского поселения по вопросу введения и использования средств самообложения граждан»**

**В соответствии с Постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 12.02.2015 г. №85 «О внесении изменений в Порядок предоставления из бюджета Республики Татарстан иных межбюджетных трансфертов бюджетам муниципальных образований Республики Татарстан на решение вопросов местного значения, осуществляемое с привлечением средств самообложения граждан, утвержденный постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 22.11.2013 N 909», Совет Бурметьевского сельского поселения Нурлатского муниципального района Республики Татарстан,**

**РЕШИЛ:**

1. Дополнить Решение Совета Бурметьевского сельского поселения от 12.01.2015 г. №87 «О назначении местного референдума на территории Бурметьевского сельского поселения по вопросу введения и использования средств самообложения граждан», пунктом 5 следующего содержания:

«Установить объем прогнозируемых доходов от средств собранных по результатам проведенного самообложения граждан в размере 281500,00 рублей.

Установить направление прогнозируемого распределения расходов от средств собранных по результатам проведенного самообложения граждан в виде:

253350,00 рублей на финансирование работ на ремонт дорог населенного пункта Бурметьевского сельского поселения;

28150,00 рублей на финансировании работ на ремонт кладбища».

2. Опубликовать настоящее решение в районной газете «Дуслык» («Дружба», «Туслах») и разместить на официальном сайте Нурлатского муниципального района в сети Интернет.

3. Настоящее решение вступает в силу со дня его опубликования.

Р.Г.Ганиев
Председатель Совета
Бурметьевского сельского поселения
Нурлатского муниципального района Республики Татарстан


**В КОНСУЛЬТАТИВНО-ДИАГНОСТИЧЕСКОМ ЦЕНТРЕ «САУЛЫК», Г. НУРЛАТ, УЛ. ЖЕМЧУЖНАЯ, 25, ВЕДУТ ПРИЕМ СПЕЦИАЛИСТЫ ИЗ Г. КАЗАНИ ПО СЛЕДУЮЩИМ НАПРАВЛЕНИЯМ:**

27 июня 2015 года
1. Взрослая, подростковая гинекология.
2. Кардиология, ревматология.
3. Неврология.
4. Врачи проведут на высокотехнологичном оборудовании исследование сердца, эхокардиоскопию с ЦДК (цветное доплеровское картирование).

28 июня 2015 года
1. Гинекология, репродуктология. Решение проблем при бесплодии. Ведение беременности.
2. Диетология.
3. Эндокринология.
4. Аллергология. Иммунология. Решение проблем при бронхиальной астме, аллергических дерматитах, кожных заболеваниях.
5. Урология. Помощь при эректильной дисфункции, ЗППП, мужском бесплодии, хр.простатите, аденоме предстательной железы.
6. Врачи проведут исследования органов малого таза, плода на 1,2 и 3 триместрах.

4 июля 2015 года
1. Гастроэнтерология.
2. Онкогинекология-эндокринология, специализация по менопаузе.
3. Отоларингология.
4. Врачи проведут на высокотехнологичном оборудовании исследование сердца, эхокардиоскопию с ЦДК (цветное доплеровское картирование), исследования сосудов головного мозга, верхних и нижних конечностей.

КДЦ предлагает услуги по ДМС через Нурлатский филиал СК «Чулпан».
Результаты обследования принимаются в БМСЭ.
Справки и предварительная запись по т.: 2-43-03, 8-927-037-40-01.
ООО «Услуга» КДЦ «Саулык». Лиц. ЛО-16-01-001191 от 30.09.2010г. ОГРН 1021605358103.
**Имеются противопоказания. Необходима консультация специалиста**
Реклама

Закупаем лом черных металлов.
Т.: 8-927-438-54-95, 8-927-428-83-88.
ООО «ОТК».

*-Профнастил*
*- Сайдинг*
*- Утеплитель*
*- Доборные элементы.*
*Доставка.*
*Выезд на замер - бесплатно.*
*Кредит АО «ОТП Банк».*
*Т.: 8-927-470-29-39, 8-987-409-27-06.*
*Универсальный рынок, м-н «Инструмент-град».*

ТЕПЛИЦЫ ОТ ЗАВОДА ПО ОПТОВЫМ ЦЕНАМ,
3*4 - 12000, 3*6 - 15000, 3*8 - 18000.
Спешите, количество ограничено!
Акция действует с 10.06.15 по 31.07.15.
Подробности акции по тел.: 89270409737, 89179239582, 89600374342.
Организатор: ООО «БулгарТрейд».